ЧӘРШӘМБЕ
24 МАРТ
1943 ел.
№ 66 (6788)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

НЫКЛЫ ДИСЦИПЛИНА — ЭШНЕҢ УҢЫШЫН ХӘЛ ИТӘ

Промышленность предприятиеләрендә тәртип һәм дисциплина өчен көрәш һәрвакытта да төп мәсьәләләрнең берсе булып килде. Хәзер, бөек ватан сугышы шартларында, бөтен халкыбыз немец-фашист илбасарларга каршы көрәш алып барган вакытта, бу мәсьәлә аеруча зур әһәмият алды.

Тәртип һәм дисциплина — производство планнарын үтәүдә хәлиткеч шарт. Кайда дисциплина яхшы куелган, шунда хезмәт җитештерүчәнлеге көннән-көн күтәрелә, эшләп чыгару торган саен арта бара. Моның шулай икәнен безнең предприятиеләрнең күп кенә алдынгы бригадалары һәм цехлары үрнәгендә күрсәтергә мөмкин. Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыккан һәм наркоматның күчмә Кызыл Байрагын алуга ирешкән предприятиеләрнең коллективлары үзләренең оешканлыклары, бердәмлекләре, тимердәй нык дисциплиналары белән аерылып торалар.

Менә партоешма секретаре урынбасары иптәш Горохов булган заводны алыйк. Аның күпчелек цехлары һәм участоклары хезмәт дисциплинасының нык булуы нәтиҗәсендә производство планнарын системалы рәвештә үтәп баралар. Мәсәлән, орденлы мастер иптәш Сөнгатуллин участогына нинди генә задание бирелмәсен, участок коллективы аны срогыннан элек үтәп чыга. Моның төп сәбәбе анда хезмәт дисциплинасының югары дәрәҗәдә булуында.

Ныклы дисциплина — эшнең уңышын хәл итә. Әгәр дә барлык предприятиеләрдә дә хезмәт дисциплинасы бүгенге көн сорауларына җавап бирерлек югарылыкта булса, безнең промышленностебыз фронтка һәм илгә продукцияне хәзергегә караганда тагын да тизрәк, тагын да күбрәк бирер иде. Ләкин, кызганычка каршы, кайбер предприятиеләрнең аерым участокларында һәм цехларында бу турыда тирәнтен уйлап җиткермиләр. Хезмәт дисциплинасы әле һаман да түбән булган, һәм шуның нәтиҗәсендә, производство планнары системалы рәвештә үтәлми торган коллективлар да бездә юк түгел.

Бу яктан караганда Казандагы киез итек-фетр фабрикасы аеруча характерлы. Фабрика бик еш кына планын үтәми. Ни өчен? — дигән сорау туар. Моңа төп сәбәпләрнең берсе — хезмәт дисциплинасының йомшак булуында, дип җавап бирергә туры килә. Узган ел анда эштән китү, прогул ясау, соңга калу, эш вакытында тик тору кебек фактлар бик күп булды. Бу елның өч аенда да андый фактлар аз кабатланмады. Ләкин, шуңа да карамастан, фабрика җитәкчелеге, партия, профсоюз оешмалары хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен чын-чынлап көрәш башлаганнары юк әле.

Партоешма секретаре урынбасары иптәш Козлов булган заводның бер цехы (начальнигы Русин) берничә айлардан бирле инде заданиесен үтәми. Анда станокларның бушка әйләнүләре, эшчеләрнең эш урынында булмыйча кайдадыр йөрүләре, төшке ашка иртә китеп соң кайтулары кебек фактлар бик еш була. Мәсәлән, 17 нче мартта мастер Иванов группасыннан 15 кеше эшне 30 минутка соңга калып башлады. 15 кешенең 30 минут эчендә бирергә тиешле продукциясен күз алдына китерегез. Бу бит производствога никадәр зыян килгән дигән сүз.

Яки менә икенче бер факт. Н-че заводның (партоешма секретаре урынбасары Закиров) начальнигы иптәш Луста булган цехында табель учеты бик начар куелган. Шуннан файдаланып, унларча кешеләр хезмәт дисциплинасын бозалар. Цех администрациясе аларның кемнәр икәнен дә белми һәм, үзеннән үзе ачык, аларга чара да күрә алмый. Партия һәм профсоюз оешмасы шундый таркаулыкка, дисциплинасызлыкка ничек түзеп торадыр—гаҗәп.

Хезмәт дисциплинасын бозучылар, производствоны таркатучылар дәүләт алдында, ватан һәм фронт алдында җинаять эшлиләр, немец-фашист илбасарларга каршы көрәш эшенә зур зыян китерәләр. Шулай ук, аларны каплап калдырырга маташучылар да, аларга каршы рәхимсез көрәш алып бармаучылар да ватан алдында зур җинаять эшлиләр. Моның шулай икәнен белә торып, хезмәт дисциплинасын бозу һәм аңа каршы чара күрмәү фактларын игътибарсыз калдырулары—югарыда күрсәтелгән предприятие һәм цех партия, комсомол, профсоюз оешмаларының һичбер нәрсә белән дә аклана алмаслык кимчелекләре.

Производствода тәртип һәм дисциплина бозучыларның хезмәт фронты дезертирлары булып саналулары турында эшчеләрнең киң катлавы арасында масса-аңлату эшләрен туктаусыз алып барырга кирәк. Тәртипсезлекнең һәм дисциплинасызлыкның бер генә факты да тикшерелмичә, чара күрелмичә калдырылмасын. Хезмәт дисциплинасын бозучылар, производствоны таркатучылар сугыш вакыты законының бөтен катылыгы белән җәза алырга тиешләр.

Хәзер Беренче Май алды социалистик ярышы бара. Ярыш йөкләмәләрен тулысынча үтәү өчен, илебезгә һәм Кызыл Армиябезгә кирәкле продукцияне җитәрлек күләмдә бирү өчен, Баш Командованиенең махсус куәтле фондын төзү өчен эшчеләр үз-үзләрен аямыйча эшлиләр. Шундый җаваплы һәм киеренке чорда хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен көрәш бер генә минутка да туктатылмаска, ә бәлки торган саен көчәйтелә барырга тиеш.

15 КОЛХОЗ ПЛАННЫ АРТТЫРЫП ҮТӘДЕ

КУКМАРА, 20 март (Телефон буенча). Районның 15 колхозы урман әзерләү планын срогыннан алда арттырып үтәделәр. Бу колхозлар буенча урман әзерләү планы 6.000 кубометр урынына 7.195 кубометр итеп үтәлде. 5.740 кубометр урынына 6.541 кубометр утын ташылды.

«Труженик» колхозы урман әзерләү планын 500 кубометр урынына 732 кубометр, ташу планын 700 кубометр урынына 1.110 кубометр, «Октябрь ялкыны» колхозы урман әзерләү планын 1.000 кубометр урынына 1.060 кубометр, ташу планын 700 кубометр урынына 830 кубометр итеп үтәде.

Я. ГАЙНУЛЛИН.

Совет Информбюросыннан

23 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

23 нче мартка каршы төндә безнең таскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

***

Көнбатыш фронтта Н-че берләшмә частьлары каты сугышлар нәтиҗәсендә халык яши торган көчле ныгытылган 3 пунктны алдылар. Немецлар, югалткан позицияләрен кире кайтарырга тырышып контратакалар ясадылар, ләкин үзләре өчен зур югалтулар белән алып ташландылар. Икенче бер участокта безнең сугышчылар дошман автоматчикларын кысрыкладылар һәм танкка каршы ата торган 3 орудие, 5 пулемет, 120 автомат һәм винтовка кулга төшерделәр.

***

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп, халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть сугышчылары дошман контратакасын кире кайтардылар һәм чигенеп баручы гитлерчылар эзеннән үк халык яши торган пунктка бәреп керделәр. Штык сугышлары нәтиҗәсендә немецлар бу пункттан бәреп чыгарылды. Сугыш кырында дошманның 200 дән артык үле гәүдәсе калды. 2 миномет батареясы, сугыш припаслары склады һәм радиостанция кулга төшерелде.

***

Белгород районында Н-че берләшмә частьлары каты сугышларда дошманның 6 танкысын һәм пехота төялгән 25 автомашинасын юк иттеләр. Икенче бер участокта безнең артиллеристлар дошманның төрле йөкләр төялгән 15 автомашинасын юк иттеләр һәм 2 немец артиллерия батареясының утын бастырдылар.

***

Чугуев районында безнең частьлар дошманга каршы ут сугышлары алып бардылар. Совет артиллеристлары немецларның бер авыр танкысын, 2 орудиеләрен җимерделәр, зур колонна немец пехотасын таркаттылар. Икенче бер участокта гитлерчылар атака ясадылар, ләкин үзләре өчен зур югалтулар белән алып ташландылар.

***

Кубаньда безнең очучылар бер көн эчендә һава сугышларында 15 немец самолетын бәреп төшерделәр. Моннан башка, зенит артиллериясе уты белән дошманның 3 самолеты юк ителде.

***

Ленинград өлкәсе районнарының берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды төнлә немец гарнизонына һөҗүм иткән. Партизаннар немецлар урнашкан 2 йортка ут төрткәннәр һәм 40 немец солдатын һәм офицерын юк иткәннәр. Ленинград партизаннарының икенче бер отряды дошманның фронт линиясенә килә торган 2 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. 2 паровоз, җанлы көчләр һәм техникалар төялгән 49 вагон һәм платформа җимертелгән. Җимерек вагоннар астында 100 гә якын дошман солдаты һәм офицеры һәлак булган.

***

Түбәндә немец-фашист кабахәтләренең Калинин өлкәсе Ржев шәһәрендә эшләгән кабахәтлекләре һәм ерткычлыклары турындагы акт игълан ителә: «Немец оккупантлар Покровский чиркәвен шакшылаганнар. Алар үз белдекләре белән чиркәүнең ишекләрен ватканнар, анда солдатлар өчен казарма ясаганнар һәм чиркәүнең барлык кыйммәтле нәрсәләрен талаганнар. Немец кан коючылар Покровский чиркәвенең священнигы Андрей Поповны атканнар. Чигенер алдыннан фашист кеше үтерүчеләр чиркәүгә миналар куйганнар һәм 200 гә якын граждан халкын аңа куып япканнар. Чиркәүгә барудан баш тартучы, яисә бара алмаучы авыру хатыннарны һәм балаларны гитлерчылар «немец хәрби властьларына каршы килүчеләр» төсендә атканнар. Немецлар халыкны чиркәүгә куып кертеп ишекләрне нык итеп япканнар һәм бинаны шартлатырга әзерләнгәннәр. Бәхеткә каршы шәһәргә бәреп кергән Кызыл Армия частьлары гитлерчыларга чиркәүне шартлатырга ирек бирмәгәннәр». Актка Покровский чиркәвенең старостасы Долгополов дьякон Тихомиров, шәһәр халкыннан Садовникова, Денисова, Морозова һәм башкалар кул куйганнар.

23 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

23 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

Баренц диңгезендә безнең корабльләр дошманның 7 000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

***

22 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның кимендә 5 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 9 сугыш припаслары складын шартлаттылар, 10 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар.

***

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че берләшмә частьлары Днепр елгасының көнбатыш ярында плацдармны киңәйтү өчен сугышлар алып бардылар. Немецлар, бу участокта бик күп артиллерия һәм миномет батареялары һәм шактый күп пехота туплап, безнең сугышчыларның алга баруларын туктатырга маташтылар һәм берничә тапкыр контратакага күчтеләр. Духовщинадан төньяктарак дошман пехотасы һәм танклары тагын да катырак контратакалар ясадылар. Совет частьлары гитлерчыларның барлык контратакаларын уңышлы рәвештә кире кайтардылар һәм 500 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар.

***

Җиздрадан төньяктарак дошман, безнең оборонабызны өзәргә маташып, уңышсыз һөҗүмнәр ясады. Нәтиҗәдә дошман бик күп җанлы көчләрен һәм техникасын югалтты. Бүген гитлерчылар совет позицияләренә атака ясауны туктаттылар. Бу участокта барган сугышлар вакытында, 19 нчы марттан башлап, немецларның 140 танкысы зарарланды һәм яндырылды, 52 орудиесе, 102 пулеметы һәм 37 минометы юк ителде. 7 000 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары үтерелде. Безнең частьлар трофейлар кулга төшерделәр һәм пленныйлар алдылар.

***

Белгород районында безнең гаскәрләр дошман танкларына һәм пехотасына каршы оборона сугышлары алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары, немецларның моторлаштырылган дивизиясенең танклар ярдәме белән ясалган атакаларын кире кайтарган чакта 400 гә якын гитлерчыларны кырдылар. Белгородтан көнчыгыш якта гитлерчылар Төньяк Донец елгасы аркылы кичтеләр һәм шактый югалтулар исәбенә халык яши торган бер пунктны алдылар. Безнең подразделениеләрнең контрударлары белән дошман бу пункттан бәреп чыгарылды һәм елганың аръягына кире алып ташланды. Сугыш кырында дошманның 200 дән артык үле гәүдәләре, сафтан чыгарылган 7 танкысы, 12 автомашинасы һәм күп кенә пехота кораллары калды.

***

Кубаньда безнең гаскәрләр, каты сугышлар нәтиҗәсендә, район үзәге Славянскаяны алдылар. Шулай ук безнең частьлар халык яши торган күп кенә башка пунктларны да алдылар. Славянская станицасы өчен булган сугышларда дошман зур югалтуларга дучар ителде. Трофейлар кулга төшерелде. Аларның саны алына.

***

Винница өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды бер тимер юл станциясенә һөҗүм иткән. Партизаннар 47 гитлерчыны кырганнар, дошманның бер паровозын һәм сугыш милекләре төялгән 8 вагонын юк иткәннәр. Чернигов елкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Һәлакәт нәтиҗәсендә дошманның күп солдатлары үлгән һәм яраланган.

21 нче мартта Берлинда сөйләгән речендә Гитлер немецлар армиясенең күпме югалтуы булганлыкны өстән генә әйтеп үткән. Азып беткән ялганчы Гитлер, икенче бөтен дөнья сугышы башланганнан бирле Германиянең 542 000 кешесе үтерелде, дип расльй Гитлерның бөлай тупас ялганлавы беренче генә түгел инде. Монда шуны искә төшереп үтәргә кирәк. 1942 нче елның 10 нчы ноябренда ул, гүяки немецлар армиясенең 350.000 кешесе үтерелгәнлекне әйткән иде. Билгеле, Гитлерның ул чактагы белдерүе дә хакыйгатьтән җир белән күк арасы кадәр ерак иде. Хәзер инде Гитлер, яңа жуликлык хәйләсе ярдәме белән, 1942—1943 нче елгы бөтен кышкы кампания вакытында немец-фашист гаскәрләрнең бары 192.000 кешеләре генә үтерелгәнлекне әйтеп, немецларны ышандырырга маташа. Бу юлы Гитлер ялганлауда барлык рекордларны узып китте. Мәгълүм ки, 1942 нче елның 23 нче ноябреннан 1943 нче елның 2 нче февраленә кадәр булган вакыт эчендә немец фашистлары армиясе Сталинград районында гына да 330.000 солдат һәм офицерларын югалтты. Шулардан 91.000 кеше плен алынды. Кышкы һөҗүмнең өч ае эчендә Кызыл Армия 700.000 нән артык дошман солдатларын һәм офицерларын юк итте һәм 300.000 нән артык кешене плен алды. Сугыш башланганнан бирле 20 ай эчендә исә немец фашистлары гаскәрләре Совет—Германия фронтында сугыш кырында үтерелгән хәлдә барлыгы кимендә 4 миллион кеше югалттылар. Гитлер үзенең ялганлавында никадәр генә шомарырга тырышмасын, совет җирләрендә үзләренә кабер тапкан миллионнарча немецлар инде Германия армиясе составыннан гомерлеккә киттеләр. Гитлер тарафыннан Советлар Союзына каршы сугышка җибәрелгән башка немецлар да шундый ук язмышка очрарлар.

Кайсы гына фронтта булсак та, нинди генә корал тотып сугышсак та, туган илебез өчен, аның азатлыгы, бәйсезлеге, намусы өчен җаныбызны аямабыз! (ФРОНТОВИК ТАТАРЛАРГА, ТАТАР ХАЛКЫННАН СӘЛАМ ХАТТАН).

ИЛ КУШКАННЫ ҮТӘРБЕЗ

Фронтовик татарларның сәлам хатка җаваплары

РӘСЕМДӘ: куркусыз сугышчы, кызылармеец К. И. Солтанов. И. авылы өчен булган бер сугышта гына да ул 18 фашистны кырды.

ТАСС фотохроникасы.

Сугыш осталыгын арттырырбыз

Татар халкының фронттагы татарларга язган хаты миндә бик зур тәэсир калдырды.

Без халкыбызның сәлам хатын Кызыл Армия дошман яуларны көнбатышка таба куып барган тантаналы көннәрдә алдык. Кызыл Армия дошманга берсеннән-берсе көчлерәк ударлар ясый. Ләкин әле дошманның көчләре тәмам сындырылып җитмәгән. Ул ярсулы каршылык күрсәтә. Ул әле яңа явызлыкларга тотынырга тырышыр. Шуңа күрә, без, сугышчан осталыгыбызны тагын да күтәрә төшеп, дошманга хәлиткеч ударлар ясау өчен, көчләребезне тагын да ныграк тупларга, дошманны тагын да ныграк кыйнарга тиешбез.

Без, дошманны илебез чикләреннән тәмам куып чыгарганчы, үзебезне аямыйча, батырларча сугышырбыз!

С. А. ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ,
Кызыл Йолдыз орденлы лейтенант.

Сез кушканча, батырларча сугышырбыз

«Төньяк - Көнбатыш фронтта очучы Камалетдинов, үз самолеты дөрләп яна башлаганы хәлдә, дошман солдатларын һәм офицерларын кырды».

Халык минем сугышчан хезмәтемне үзенең хатында әнә шулай билгеләп үтә. Совет сугышчысы өчен, халык игътибарыннан да, халык хөрмәтеннән дә бөек нәрсә юк. Халык хөрмәте, халык ышанычы аны тагын да зуррак батырлыкларга дәртләндерә. Чөнки халык сүзе—ата сүзе.

Без, дошманның Демянск плацдармын бетергәндә, халкыбызның безгә баглаган өметләрен истә тотып эш иттек. Немец шакшылары безнең изге җирләребезне, авылларыбызны, шәһәрләребезне талап, яндырып, зыян-зарарсыз гына качарга уйлаганнар иде. Бездә совет халкы биргән куәтле канатлар бар. Дошман нинди генә тизлек белән качарга маташса да, без аны барыбер куып җитәбез. Ул бездән котыла алмый.

Мин, үз самолетым белән, тугыз бомбардировщик составында очтым. Дошман кулындагы тимер юл станциясенә һөҗүм иткәндә, без бер удар ясап, дошманның 3 эшелонын җимердек. Дошман оборонасының алгы өлешенә һөҗүм иткәндә, ике удар ясау белән, дошманның 11 ДЗОТ ын җимердек.

Дошман транспортларына һөҗүм ясаганда, минем бер бомбам ике автомашинага туп - туры төшеп, аларны көлгә әйләндерде.

Мин бу һөҗүм көннәрендә егермедән артык уңышлы сугышчан очыш ясадым.

Явыз дошманга каршы без, Совет илендәге кардәш халыкларның уллары, бер сафта торып көрәшәбез. Минем экипажым составы да моңа ачык мисал. Минем штурманым — еврей егете иптәш Слуцкер Лев Борисович, укчы-радистым — украин егете Головко Михаил Григорьевич. Без һәммәбез дә, бер атаның балаларыдай, бердәм булып эшлибез.

Безнең сугышчан хезмәтләребезгә Совет Хөкүмәте югары бәя бирде. Мин үзем Кызыл Байрак ордены һәм Ватан Сугышы ордены белән бүләкләндем, Слуцкер һәм Головко Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнделәр.

Минем командалыгымдагы баш ка самолетларның экипажлары да орден һәм медальләр белән бүләкләнделәр.

Соңгы көннәрдәге уңышлы очышлар өчен, командование безгә рәхмәт белдергән иде. Бу көннәрдә тагын бер шатлыклы хәбәр килде: татар халкының хатын алдык, аның хөрмәтенә ирештек.

Кадерле ата һәм аналарыбыз, сөекле сеңел һәм туганнарыбыз!

Сезнең чын күңелдән әйтелгән сүзләрегез безнең дә йөрәкләребезгә килеп җитте. Без туган җирләребезне немец шакшыларыннан тулысынча азат иткәнче, сез кушканча, батырларча сугышырбыз.

Өлкән лейтенант
ИСКӘНДӘР КАМАЛЕТДИНОВ.

ДОШМАННЫ РӘХИМСЕЗ КЫЙНАРБЫЗ

Татар халкының хатын без, сугышчылар җыелышып укыдык. Бу хат безгә, тылдагы туганнарыбызның фронт өчен җиң сызганып эшләүләрен тагын бер кат күрсәтте.

Мин сугышка кадәр Казанда Н-че заводта мастер булып эшләдем. Мин атам һәм анам да гомерләре буена шунда эшләделәр. Хәзер апам анда эшли. Үзем сугышның беренче көненнән бирле фронтта.

Халкыбызның хатына җавап итеп, үз өстемә алган эшләрне отличнo үтәргә, явыз дошманны рәхимсез кыйнарга сүз бирәм.

Сержант **РӘШИТ УРАСКУЗИН.**

Н-че заводның иң яхшы бригадирларыннан берсе булган иптәш И. Салеев заводта бик күп яшь кадрлар тәрбияләде. **РӘСЕМДӘ:** иптәш Салеев (уртада) үзенең өйрәнчекләренә—хәзер инде стахановчы-өчйөзпроцентчы яшь эшчеләргә яңа заданиене аңлата.

К. Тахтеев фотосы.

КОМСОМОЛ ТОРМЫШЫ

КЕШЕЛӘРНЕҢ ЙӨРӘГЕНДӘ ХЕЗМӘТ ДӘРТЕ КАЙНЫЙ

ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы иптәш Яковлев булган Н-че заводның комсомолецлары социалистик ярышта алда баралар һәм үзләренең эш үрнәкләре белән союздан тыш яшьләрне шуңа туплыйлар. Беренче Май алды ярышы уңае белән заводның комсомолецлары һәм союздан тыш яшьләре стахановчы вахтага бастылар. Күп кенә цехларда фронт бригадалары оештырылды. Бу бригада яшьләре стахановчы хезмәтнең гүзәл үрнәкләрен бирәләр.

Түбәндә без яшьләрнең батырлык эшләрен күрсәткән кайбер материаллар бирәбез.

ГВАРДЕЕЦЛАРЧА ЭШЛӘРГӘ

Комсорг иптәш Дарвин булган цехның икейөзпроцентчы яшьләре, генерал-майор иптәш Родимцев булган гвардия часте сугышчыларына, командирларына хат яздылар. Бу хатта алар тылда гвардеецларча эшләп, немец-фашист бандитларга үлем китерүче продукцияне торган саен күбрәк бирергә дигән йөкләмә алдылар. Шуны үтәү йөзеннән цехларда фронт бригадалары оештырылды. Хәзер бу бригадалар үзләренең үрнәкле эшләре белән бөтен завод күләмендә дан казануга ирештеләр.

Менә яшь мастер комсомолец Рулькевич бригадасы. Ул элек арттa калып бара торган бригада иде.

— Ватан алдындагы, фронт алдындагы бурычны үтәү өчен, фронтка продукция җитештерү өчен барлык көчебезне бирергә тиешбез,—диде иптәш Рулькевич үзенең иптәшләренә.

Яшьләр аның сүзен күтәреп алдылар һәм ныклап эшкә керештеләр. Һәркөнне смена соңында бригаданың җыелышы үткәрелде. Эшләнгән эшләргә йомгак ясалды. Алдынгыларның тәҗрибәләрен уртаклашу, артта калучыларга практик ярдәм оештырылды.

Тырышлык үзенең матур нәтиҗәләрен бирде. Хәзер бу бригада алдынгылар сафына басты.

Алдынгы стахановчылар заводның барлык яшьләренә мөрәҗәгать итеп, социалистик ярышны тагын да киң җәелдерергә, фронт өчен кирәк булган продукцияне торган саен күбрәк җитештерергә чакырдылар.

Комсомол оешмасы заводның алдынгы сафта булуы өчен көрәштә комсомолецларның һәм союздан тыш яшьләрнең тагын да нәтиҗәлерәк эшләүләре өчен көрәшер. Безнең патриотик бурыч әнә шундый.

Р. ЗАЛЮШЕВ,
Заводның комсомол оешмасы секретаре.

СТАХАНОВЧЫ ЦЕХТА

Хәзер безнең завод коллективы 1 нче Май бәйрәмен лаеклы рәвештә каршылауга әзерләнә. Фронтка, Кызыл Армиябезгә ярдәмне тагын да көчәйтү өчен социалистик ярыш киң җәелдерелде. Бу ярышта комсомолецлар, союздан тыш яшьләр алгы сафта баралар.

Иптәш Сталинга Советлар Союзы Маршалы исеме бирү турындагы Указны укыгач, комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр стахановчы вахтага бастылар. Алар производство планын арттырып үтәргә, Кызыл Армиянең Баш Командованиесенең махсус фонды ва планнан тыш продукция җитештерергә йөкләмә алдылар.

Йөзләрчә патриот яшьләр үзләренең сүзләрен практик эшләр белән аклыйлар. Комсомолец токарь иптәш Измайлов һәркөнне икешәр норма бирә. Комсомолец слесарь Вавилов планда күрсәтелгәннән 4 тапкыр артык продукция эшләп чыгара. Комсомолец Дмитренко аеруча зур уңышларга иреште. Ул норманы 450—500 процентка үтәп, заводның алдынгы слесаре дигән мактаулы исемне яулап алды.

Мин үзем, ФЗУ мәктәбендә укып, слесарьлык профессиясен үзләштердем. Хәзер норманы 5 тапкыр арттырып үтим. Соңгы вакытта үземнең профессиямә 2 яшь эшчене өйрәттем. Хәзер алар үзләре эшли башладылар.

Безнең завод комсомолецлары һәм союздан тыш яшьләре әнә шулай эшлиләр. Бурыч—тагын да яхшыракэшләүдән гыйбарәт.

М. ВӘЛИӘХМЕТОВ,
Яшь стахановчы.

ХАЛЫК ХАТЫ

Бүлмәдә тирән тынлык. Шушы тынлык эчендә, татар сугышчылары үз илләреннән, үз халыкларыннан килгән сәлам хатны тыннарын да алмыйча тыңлыйлар. Аларның күз алларына туган - үскән авыллары, Татарстанның киң кырлары, гөрләп эшли торган заводлары-фабрикалары килеп баса. Фронтка киткәндә үзләрен озатып калган ата-аналарының, хатын һәм апа-сеңелләренең соңгы тапкыр әйткән сүзләре исләренә төшә.

Халкыбызның данлы тарихы Ливон сугышыннан алып, хәзерге ватан сугышына кадәр, килмешәк немец басып алучыларына каршы көрәштә күрсәткән каһарманлыклары, тыңлаучыларның сугышчан дәртләрен канатландыра.

Политик эш буенча начальник урынбасары иптәш Бердичевский булган подразделениедә 40 лап яралы татар сугышчысы, татар халкының сәлам хатын шушылай зур дикъкать һәм игътибар белән тыңладылар. Сәлам хат буенча уздырылган митинг-беседа вакытында, сугышчылар күп сораулар бирделәр, хаттагы аерым моментлар буенча сөйләделәр. Куркусыз старшина Курмаевның геройларча үлеме, сугышчыларны аеруча дулкынландырды. Берничә сугышчы бу турыда сорау бирде. Өлкән лейтенант иптәш Фәйзерахманов сүз алып, түбәндәгеләрне әйтте:

— Курмаев чын батырларча үлгән. Ул ахыр чиккә кадәр сугыша һәм немец автоматчиклары кулына бирелмәс өчен, күкрәгенә куйган гранатасы белән үзен дә һәм немецларны да шартлата. Курмаевның бу хәрәкәте, чыга алмаслык авыр хәлгә төшү аркасында чарасыз калып эшләнгән эш кенә түгел. Курмаев дошман кулына бирелергә теләмәде, аның сугышчан намусы моңар ирек бирмәде. Аннары ул, ахыр сулышында да, үзе үлгән чагында да, дошманны кырып бетерергә теләде. Аның геройларча үлемен татар халкы мәңге онытмас.

Хат буенча аңлашуларга сугышчылардан Гыйльманов, Хәлил Әхметов, лейтенант Биков һәм башкалар катнаштылар.

Сәлам хат астына куелган имзалар да сугышчыларны бик кызыксындырды. Алар монда кул куючылар арасында атаклы галимнәр, артист һәм колхозчылар белән беррәттән, үз колхозларындагы танышларын, бергә эшләгән иптәшләрен дә таптылар. Мәсәлән, Татарстанның Саба районыннан килгән ике сугышчы, Хәлил Әхметов һәм Гыйльманов, сәлам хатка кул куючылардан Саба районы «Игенче» колхозы бригадиры Нуриеваны бик яхшы беләләр. Шушы уңай белән, алар үзләренең сугышка кадәр ничек эшләүләрен искә төшереп, сөйләделәр.

Кызылармеец Хәлил Әхметов, сәлам хатка куелган имзалар турында шушы сүзләрне әйтте:

— Сәлам хатка 1.511,137 кеше кул куйган. Татарстанда 63 район бар. Һәр районда уртача 50 авыл исәпләгәндә, хатка һәр авылдан 500 гә якын кеше кул куйган була. Болай булгач, бу хатка минем әти дә, әни дә һәм башка туганнарым да кул куйганнар. Бу минем якыннарым тарафыннан миңа каратып язылган сәлам хат. Аның һәр сүзе миңа якын, минем өчен изге. Ул хаттагы наказны үтәү безнең бурыч.

Иптәш Әхметовның бу сүзләре сугышчыларга тирән йогынты ясады. Алар, сәлам хатның үзләренә иң якын кешеләр тарафыннан, үзләренең сөекле ата-аналары, хатын һәм бала-чагалары, туган-тумачалары, күрше-коланнары тарафыннан язылган кадерле документ булуын бик яхшы төшенеп, сугышта батыр һәм гайрәтле булырга, дошманны аяусыз кыйнарга һәм тәмам җиңгәнче сугышырга сүз биреп таралдылар.

Кызылармеец
Ш. МӨДӘРРИСОВ.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

САБАН ӨСТЕ КИЛЕП ҖИТӘ!

Язгы чәчүне отлично әзерлек белән каршы алу һәм отлично үткәрү — фронтның җитди таләбе. Бу таләпне намус белән үтик, немец илбасарларның үлемен якынайтыйк!

Азнакай районы, „Октябрь бүләге" колхозы иптәш К. Зариповага

Татарстан АССР Җир Эшләре Халык Комиссариаты һәм аның политсекторы Сезне туган илезне яратуыгызны һәм аңа карата булган патриотик хисләрегезне чагылдырып, үзегезнең колхозыгызның чәчүлек орлык фондына 180 пот ашлык биреп торуыгыз өчен чын күңелдән котлый. Сездән үрнәк алу—Татарстандагы барлык колхозчыларның һәм колхозчы хатын-кызларның бурычы.

ТАССР Җир Эшләре Халык Комиссары Ә. ХӨСӘЕНОВ.
Политсектор начальнигы С. ГОНЧАРОВ.

Комсомолка иптәш К. ЗАРИПОВАГА

ВЛКСМ нын Татарстан Өлкә Комитеты Сезне язгы чәчүгә әзерлектә актив катнашуыгыз һәм запас ашлыгыгыздан үзегезнең колхозыгызның орлык фондына 180 пот ашлык бирүегез өчен кайнар рәвештә котлый. ВЛКСМ Өлкә Комитеты Сезнең киләчәктә дә үзегезнең колхозыгызга язгы чәчүне яхшы сыйфатлы итеп срогында башкаруда һәм югары хәрби уңыш алуда гадел хезмәтегез белән булышуыгызга ышана. Комсомолларча сәлам белән

ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре Б. ЛУЦКЕР.

КОЛХОЗЧЫЛАР ТӘКЪДИМЕ БЕЛӘН

ТЕЛӘЧЕ, 23 март. (Телефон буенча). «Кызыл Кукчә» колхозында чәчүлек орлык җитешмәү куркынычы бар иде. Колхоз правлениесе бу мәсьәләне тикшергәндә колхозчы актив белән киңәште. Правление утырышында иптәш Галиева сүз алды. Ул:

— Орлыклык ашлык өчен читкә чыкмабыз инде. Аны үзебезнең авылдан табарга мөмкинлек бар. Менә мин үзем 7 пот ашлык һәм бер центнер бәрәңге биреп тора алам,—диде. Аннан соң иптәш Гәрәев тә 24 пот ашлык, 60 пот бәрәңге бирә алуы турында белдерде.

Колхозчыларның тәкъдиме белән тиз арада чәчүлек орлык өчен 23 центнер ашлык, 24 центнер бәрәңге тупланды. М. МЕДВЕДЕВ.

Мөһим бурычны үтәгәндә

БАЛТАЧ, 23 март. (Телефон буенча). Орлык туплау—язгы чәчүгә әзерлекнең мөһим участогы. Декада көннәрендә, колхозларның чәчүлек мәйданына җитәрлек кадәр орлык әзерләү өчен районда күп кенә чаралар үткәрелә. Бу эшне оешкан төстә алып бару өчен колхозларда махсус бригадалар төзелде. Район активыннан авылларга вәкилләр дә җибәрелде.

Орлык туплауда колхозчыларның булышлыгы бик зур. «Кызыл игенче» колхозы членнары үзләренең гомуми җыелышларында:

— Колхозыбызны орлык белән тәэмин итәрлек хәлебез бар. Бер карыш җиребез дә чәчелми калмас,—диделәр һәм шул көнне үк үзләренең запасларыннан 40 центнер ашлык һәм 20 центнер бәрәңге җыеп китерделәр. Беренче булырак, иптәш Салахова 18 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге кертте. Галиева һәм Камалова иптәшләр дә аңардан калышмадылар. Алар 18 әр пот ашлык һәм 18 әр пот бәрәңге бирделәр.

Үзләрендә орлык җитәрлек кадәр әзерләнгән колхозлар да бу хәрәкәттән читтә калмадылар. «Вильтурис» колхозы «Кызыл Алан»колхозына 60 центнер орлык бирде. Колхозчылардан Яковлев һәм Егоров иптәшләр 18 әр пот орлык, 18 әр пот бәрәңге тапшырдылар. Нәтиҗәдә, декаданың беренче көннәрендә район буенча 200 центнердан артык ашлык, 1.800 центнер бәрәңге орлыгы тупланды.

Язгы чәчүгә әзерлекнең уңышлы тәгәлләнүе колхозларга җибәрелгән вәкилләрнең һәм андагы агитаторларның яхшы эшләүләренә бәйләнгән. Ләкин кайбер вәкилләр бу эштә үзләрен җаваплы санамыйлар. «Кызыл чишмә» колхозына вәкил итеп җибәрелгән Нәби иптәш Шакиров колхозга бу өлкәдә практик ярдәм күрсәтми. Биредә авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тәгәлләнмәгән. Атларның хәлен яхшырту чаралары күрелми. Чәчүлек орлык чистартылмаган. Орлыкның җитәрлек булмавына да карамастан, орлык туплау декадасы биредә башланмаган да әле.

Декаданың уңышлы нәтиҗәләр бирүе колхозчылар арасында аңлату эшләренең яхшы куелуын таләп итә. Янгул авылы агитаторы иптәш Нәҗипова исә үзенә тапшырылган эшне үтәүгә җавапсыз карый. Ул, декаданы үткәрүгә бик пассив катнаша. Партиябез һәм хөкүмәтебезнең күрсәтмәләрен колхозчыларга аңлату эше белән шөгыльләнми.

Икенче хәрби язны каршылаганда болай гамьсезлек һәм булдыксызлык күрсәтү ватанга хыянәт итү белән бер. Намусын югалтмаган кеше шушындый җаваплы чорда пассивлык күрсәтмәскә тиеш.



Арча МТС ында оештырылган тракторчылар курсында. РӘСЕМДӘ: уку отличникларыннан бер группа. Сулдан уңга—Г. Хәсәнов, Х. Вәлиуллина, Р. Вәлиева һәм Х. Шәмсиева иптәшләр.
И. Папков фотосы.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

(1943 нче ЕЛНЫҢ 20 нче МАРТЫНА)
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	100,0	56. Буа	75,9
2. Чокалы	100,0	57. Кызыл Чапчак	75,0
3. Актаныш	100,0	58. Беренче Май	74,5
4. Бөгелмә	100,0	59. Баулы	74,1
5. Нөркәй	100,0	60. Әтнә	74,0
6. Алга	100,0	61. Ютазы	74,0
7. Тымытык	100,0	62. Теләче	73,5
8. Алабуга	100,0	63. Солтан	73,5
9. Тирсә	100,0	64. Зирекле	73,1
10. Ишеево	100,0	65. Кәкре елга	72,0
11. Чүпрәле	100,0	66. Шөгер	71,7
12. Дөбьяз	100,0	67. Әлмәт	70,8
13. Яниль	100,0	68. Столбище	70,4
14. Олы Кариле	100,0	69. Буденный	70,2
15. Юдино	100,0	70. Питрәч	70,2
16. Юртыш	100,0	71. Тәкәнеш	69,8
17. Исәнбай	100,0	72. Әхмәт	68,6
18. Т. Тамак	100,0	73. Мөслим (Чистай)	67,7
19. Мөрәле	100,0	74. Казанбаш	66,7
20. Зөя	100,0	75. Маткавыш	65,5
21. Чистай	98,0	76. Черемуховский	64,8
22. Саба	96,0	77. Морт	64,7
23. Поповка	95,0	78. Кызыл юл	64,4
24. Октябрь	94,8	79. Балык бистәсе	64,4
25. Кадряк	91,9	80. Биләр	63,[illegible]
26. Дәүләки	91,3	81. Каргалы	63,3
27. Норлат	90,5	82. Ромадан	63,0
28. Чүрибураш	89,4	83. Алексеевский	63,0
29. Сарман	88,7	84. Арча	62,8
30. Заинский	87,9	85. Әлки	62,5
31. Кузайкино	87,3	86. Макыл	62,3
32. Тархан	86,9	87. Майдан	62,1
33. Соколка	86,3	88. Чиябаш	61,9
34. Б. Матак	86,3	89. Константиновка	61,5
35. Кичү	85,7	90. Иске Чишмә	61,4
36. Чаллы	85,5	91. Минзәлә	60,9
37. Чыбыклы	85,4	92. Чишмә	60,6
38. Иске Тимошкино	84,2	93. Карамалы	60,0
39. Чаллы	83,8	94. Тат. Ялтан	59,1
40. Азин	83,3	95. Үзәк	58,8
41. Димитров	82,9	96. Мамадыш	58,1
42. Акташ	82,8	97. Кама тамагы	56,7
43. Бондюг	82,2	98. Зур Поляна	56,1
44. Аксубай	82,1	99. Салман	55,3
45. Кукмара	82,1	100. Тат. Ходяш	54,2
46. Калинин	82,0	101. Иске Писмән	53,3
47. Кызыл Йолдыз	81,9	102. Кузнечиха	52,4
48. Тәтеш	79,2	103. Кошкино	52,2
49. Куйбышев	78,9	104. Трехозерский	50,9
50. Балтач	78,8	105. Ключи	48,3
51. Тельман	78,7	106. Бикчтау	43,7
52. Әлшә	78,6		
53. Яңа Чишмә	78,4	Барлыгы:	77,1
54. Рождественский	78,1	1943 нче елның 15 нче	
55. Мәлки	76,0	мартына	73,7

ТРАКТОРЧЫЛАРГА ЯРДӘМГӘ

Комбинацияләштерелгән трактор отряды турында

Язгы көне сөрелә торган җиргә чәчү өчен комбинацияләштерелгән трактор агрегаты сабаннан, тырма һәм чәчү машинасыннан тора. Мондый агрегат «сөрү-чәчү агрегаты» дип атала. Әгәр дә җир көздән туңга сөреп калдырылган булса, агрегатта сабан урынына культиватор тагыла. Мондый агрегат «чәчү агрегаты» дип йөртелә.

Комбинацияләштерелгән агрегат бер үк вакытта берничә эшне башкара.

Гадәттә практикада киң күләмдә кулланыла торган специальләштерелгән агрегат еш кына хәлләрдә трактор өчен тулы нагрузка була алмый. Мәсәлән, «ХТЗ» тракторыннан һәм өч корпуслы сабаннан торган агрегат булганда еш кына хәлләрдә тракторның тарту көченнән бары 66 проценттан 89 процентка кадәр генә файдаланыла. Ә 24 рәтле бер чәчү машинасы гына тагып эшләгәндә, шул ук тракторга нагрузка 50 — 60 процентттан артмый. Специальләштерелгән агрегатта бу кимчелекне бетерергә дә мөмкин булмый. Мәсәлән, «ХТЗ» тракторына 3 корпуслы сабан урынына 4 корпуслы сабан таксаң да һәм шулай ук 24 рәтле бер чәчү машинасы урынына 24 рәтле ике чәчү машинасы таксаң да тарта алмый. Моннан котылуның, ягъни тракторга тулырак нагрузка биреп, аның көченнән тулырак файдалануга ирешүнең юлы бар. Моның өчен, специальләштерелгән агрегатка өстәмә рәвештә төрле исемдәге кораллар тагарга, икенче төрле әйткәндә, комбинацияләштерелгән агрегат оештырырга була.

Комбинацияләштерелгән агрегат белән эшләгәндә тракторның көнлек заданиесен дә һәм шулай ук сезон заданиесен дә үтәргә генә түгел, арттырып үтәргә була. Тракторга тулы нагрузка бирү һәм ике—өч төрле эшне бер үк вакытта башкару белән тракторның бушка йөрүен кыскарту нәтиҗәсендә ягулыкка да шактый зур экономия ясала. Сөрү, тырмалау һәм чәчү эшләрен бер үк вакытта алып бару туфракта дымның сакланып калуына һәм, димәк, иген уңышының күтәрелүенә хезмәт итә. Комбинацияләштерелгән агрегатның әһәмияте әнә шунда.

1942 нче елны Татарстан АССР дагы күп кенә МТС ларда чәчү агрегатлары да, шулай ук сөрү-чәчү агрегатлары да кулланылды.

«ЧТЗС—65» тракторына көйләнгән сөрү-чәчү агрегатына Алабуга МТС ында 5 корпуслы ике сабан, 6 звено тырма һәм 28 рәтле чәчү машинасы тактылар. Бу МТС та мондый агрегатлар 3 иде. Шул ук Алабуга МТС ы хезмәт күрсәтә торган «Вторая пятилетка», «Власть Советов», «Пролетарий» һәм башка күп кенә колхозларда «СТЗ» тракторына комбинацияләштерелгән 12 агрегат эшләде. Бу агрегатларның һәрберсе 4 корпуслы сабаннан, ике звено тырмадан һәм 10 рәтле чәчү машинасыннан гыйбарәт иде.

Калинин МТС ында «ЧТЗС—65» тракторына ике чәчү агрегаты оештырдылар. Аларның һәрберсе 17 табанлы өчәр культиватордан, 12 звено тырмадан һәм 24 рәтле 3 чәчү машинасыннан гыйбарәт иде. Киң алымлы мондый чәчү агрегатлары беренче буларак 1940 нчы елны Куйбышев өлкәсенең Сызрандагы орлык совхозында кулланылган иде. Анда бу агрегатларны «Чәчү комбайны» дип исемләделәр. «Чәчү комбайны»н куллану нәтиҗәсендә, уртача эшләп чыгарыш йомшак җир сөрүгә күчереп исәпләгәндә 17,6 гектардан 32,3 гектарга күтәрелде. Шул ук вакытта һәрбер гектарга 1,5 килограмм ягулыкка да экономия килеп чыкты. «Чәчү комбайны»н куллану һәр гектардан 2,6 центнер өстәмә уңыш алырга мөмкинлек бирде.

Чәчү һәм сөрү-чәчү агрегатларын 1943 нче елның язында куллану гаять әһәмиятле чара булачак. Барлык МТС ларда да ул агрегатлардан киң күләмдә файдаланырга тиешләр. Бу уңай белән тагын шуны әйтергә кирәк: агрегатка керә торган төрле исемдәге коралларның алым киңлекләре тигез булырга һәм аларның бөтенесен җыйганда тракторның тарту көченә тулысынча туры киләрлек булырга тиеш. Алым киңлекләрен көйләгәндә чәчү машиналарындагы берничә торонне бикләп куярга, ә сабаннарда артык корпусларны алып ташларга мөмкин.

Безнең Татарстан МТС лары шартларында комбинацияләштерелгән агрегатлар кулланылган булсалар да, күп кенә тракторчылар өчен бу яңа нәрсә булып тора. Шуңа күрә комбинацияләштерелгән агрегатта эшләү өчен тәҗрибәле тракторчыларны билгеләргә һәм агрегатлар өчен тигез һәм озынча участоклар аерып куярга кирәк.

Доцент С. ИЛЬИН.

ГИТЛЕР КОМАНДОВАНИЕСЕНЕҢ ТАГЫН БЕР ЯЛГАНЫ

Соңгы вакытларда гитлерчы ялганчылар һәртөрле ялган «хәрби белдерүләр» эшләп чыгаруда аеруча тырышлык күрсәтәләр. Алар, бер каләм селтәнү белән, дистәләрчә совет пехота берләшмәләрен, моторлаштырылган берләшмәләрне һәм танк берләшмәләрен кәгазьдә юк итеп ташлыйлар.

Мәсәлән, 20 нче мартта Германия информация бюросы бер ялган белдерү игълан итте. Бу белдерүдә, 13 нче февральдән бирле булган вакыт эчендә Төньяк Донец белән Днепр арасындагы районда гүяки советларның 9 укчы дивизиясе, 6 укчы бригадасы, 4 кавалерия дивизиясе, 9 моторлаштырылган бригадасы, 25 танк бригадасы, 2 танк полкы һәм бер танкка каршы пушкалар бригадасы юк ителгәнлеге әйтелә. Ләкин ялганчы немецларга бу да аз күренгән. Аннан соң бу белдерүдә, шуның өстенә тагын Кызыл Армиянең 19 укчы дивизиясенең, 18 моторлаштырылган һәм танк бригадаларының, шулай ук башка берләшмәләренең һәм частьларының зур югалтуларга дучар булганлыклары әйтелә.

Үтәли ялган булган бу белдерүгә дөреслек кыяфәте кертү өчен лыгырдык немецлар советларның гүяки юк ителгән дивизияләренең һәм бригадаларының номерларын үзләренең башларына ничек туры килсә шулай санап чыгалар.

Гитлерчылар ялганлауның чигенә барып җиттеләр һәм узып та киттеләр. Монда шуны әйтү дә җитә: Төньяк Донец белән Днепр арасындагы районда Германия информация бюросы белдерүендә әйтелгән кадәр санда совет берләшмәләре беркайчан да булмады. Юк ителгән дип белдерелгән совет дивизияләре һәм бригадалары составына гитлерчылар тарафыннан кертелгән кайбер дивизияләр һәм бригадалар Кызыл Армия составында бөтенләй юк иде, ә күпләре көньяктагы сугышларда катнашмадылар һәм шуңа күрә аларның юк ителүләре һәм югалтуларга дучар булулары мөмкин түгел иде.

Немецлар командованиесе, совет гаскәрләрен чолгап алырга һәм аларга «немецча Сталинград» ясарга маташып, февраль ахырында Төньяк Донец белән Днепр арасындагы районда каршы һөҗүмгә күчкән иде. Моның өчен немецлар сугышлар бара торган районга Көнбатыш Европадан бик күп яңа пехота һәм танк дивизияләре китерделәр, шулай ук үзләренең туздырылган берләшмәләрен тулыландыру өчен Германиядән 110—115 марш батальоны китерделәр.

Гомумән хәзер немецлар Сталинград өчен үч алу турында хыялланалар, ләкин алар бернәрсә дә эшли алмадылар һәм аларның ниятләре бөтенләй җимерелде. Безнең гаскәрләр, бик каты тоткарлау сугышлары алып барып һәм дошманны авыр югалтуларга дучар итеп, командованиенең приказы буенча яңа оборона линиясенә күчтеләр һәм шулай итеп немецларның планнарын өзделәр.

Бу сугышлар барышында безнең гаскәрләрнең 36.722 кешесе үтерелде һәм хәбәрсез югалды.

Шул ук вакыт эчендә безнең гаскәрләр немецларның кимендә 52.000 солдат һәм офицерын юк иттеләр.

Төньяк Донец белән Днепр арасында булган сугышларның чын йомгаклары әнә шулар.

Шулай булгач совет гаскәрләренең югалтулары турында гитлерчылар белдерүенең ялган икәнлеге һәм Совет-Германия фронтында немец-фашист гаскәрләрнең җиңелүе турындагы белдерүләрдән соң әле һаман да аңына килә алмый торган Германия халкын юату һәм алдау өчен уйлап чыгарылганлыгы ачык түгелме?

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Сталинградны аякка бастыруга ярдәм итик

Сталинград районында сугышлар бетте. Фашистик бандитлар көнбатышка алып ташландылар. Идел буендагы бу героик шәһәр авыр сугышлардан соң, немец ерткычлар тарафыннан җимерелгән хуҗалыгын яңадан аякка бастыру һәм үзенең авыр яраларын төзәтү эшенә керешә.

Сугышчан шәһәрне тизлек белән аякка бастырырга, аның промышленностен һәм авыл хуҗалыгын тормышка кайтарырга кирәк. Моның өчен бөтен көчне, барлык мөмкинлекләрне мобилизацияләү таләп ителә. Герой шәһәрне аякка бастыру эшенә якыннан торып ярдәм итү һәрбер совет патриотының изге бурычы. Без Сталинградка төрле төзү материаллары, җиһазлар, кием-салым, аяк киемнәре, авыл хуҗалыгы инвентаре, орлык, терлек, ашамлык продуктлары, медикаментлар, уку әсбаплары һәм квалификацияле кадрлар: врачлар, укытучылар, тракторчылар, комбайнчылар, монтаж һәм төзелеш эшчеләре бирергә тиешбез.

Иваново өлкәсенең хезмәт ияләре Сталинград шәһәренең бер промышленность районын һәм өлкәнең ике авыл хуҗалыгы районын шефка алып зур патриотлык үрнәге күрсәттеләр. Алар бу районнарда халык хуҗалыгын үз көчләре белән аякка бастыруны өсләренә алдылар. Ивановочылар инде бу районнарга бик күп төрле төзү материаллары, предприятиеләр өчен җиһазлар, запас частьлар, авыл хуҗалыгы инвентаре, кием-салым, ашамлык продуктлары җыеп җибәрделәр.

Орденлы Татарстанның эшчеләре, колхозчылары һәм барлык хезмәт ияләре бу патриотик хәрәкәттән читтә калмаска, Сталинград шәһәрен һәм аның районнарын аякка бастыру эшендә актив катнашырга тиешләр. Республикабызның һәрбер предприятиесендә, һәрбер колхозында һәм һәрбер промышленность артелендә героик шәһәргә ярдәм итү өчен зур мөмкинлекләр бар. Бу эшне уңышлы итеп башлап җибәрү өчен, иң беренче чиратта урыннарда үзләреннән артык, ләкин Сталинград өчен, аның районнарын аякка бастыру өчен гаять кирәкле әйберләрне тизлек белән учетка алырга, предприятиеләрдә һәм мастерскойларда эш вакытыннан тыш запас частьлар һәм инструментлар ясауны оештырырга кирәк. Хезмәт ияләре арасында Сталинградка ярдәм фондына средство һәм әйберләр җыюны кичекмәстән башлап җибәрергә, бигрәк тә яшьләрдән Сталинградны аякка бастыру эшендә турыдан-туры катнашырга теләүче иптәшләрне табарга кирәк.

Сталинград эре тимер юл һәм су юлы узелы булып исәпләнә. Шулай булгач, Казан тимер юлчылары һәм республикабызның су юлы транспорты работниклары бу мактаулы эштән читтә калмаслар, Сталинградның тимер юл һәм су юлы транспортын аякка бастыруда конкрет эш белән ярдәм итәрләр.

Ивановочылардан үрнәк алып, безнең Татарстан республикасы да Сталинград шәһәренең бер промышленность районын һәм өлкәнең ике авыл хуҗалыгы районын шефка алырга тиеш. Шуның белән бергә предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, районнарда һәм колхозларда Сталинградка ярдәм итү группалары оештырылырга, азат ителгән герой шәһәрне аякка бастыру өчен күбрәк һәм тизрәк ярдәм итү буенча үзара социалистик ярыш җәелдерелергә тиеш.

Ф. КОВАЛЬСКИЙ.

ЧЕРЧИЛЛЬНЕҢ РАДИО БУЕНЧА ЧЫГЫШЫ

ЛОНДОН, 21 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген Англиянең баш министры Черчилль радио буенча речь белән чыккан.

Черчилль, сугыш тиздән бетәр дип уйлаучы кешеләрнең фикере белән кушыла алмавын белдергән. Аннары ул болай дигән:

— Бүген мин сугышның барышы турында бер сүз дә әйтмим һәм, политик каршылыкларны гадиләштерә һәм йомшарта алырмын дип ышанган хәлдә, кайбер сугыштан соңгы һәм эчке мәсьәләләргә генә кагылып үтәм. Барыннан да элек без хөкүмәтне яки бездән соң булачак кешеләрне үзләренең кулларын бәйләргә ышандырырга яки хәтта шуңа мәҗбүр итәргә маташулардан сак булырга тиешбез. Аларның беркемгә дә билгеле булмаган һәм, ихтимал, дәүләткә озак елларга шул замандагы хәлләр белән акланмаслык гаять зур яңа расходлар тагачак хәлләргә төшерүләре мөмкин.

Хәзерге вакытта үзебез нык басып тора торган биеклекләргә килеп җиткәнчегә кадәр миңа ышанып килгән һәм кыенлыклар аркылы минем артымнан ияреп барган кешеләргә, ягъни сезгә, мин бернинди дә вәгъдәләр бирмәскә һәм бернинди дә әкиятләр сөйләмәскә карар бирдем. Ләкин безнең бурычыбыз—килеп чыгуы ихтимал булган хәлләргә хәзер торырга тырышып караудан гыйбарәт булырга тиеш. Бик саклык белән һәм пәйгамбәрлек итмичә генә әйткәндә, мин, киләсе елга кайчан булса да, ихтимал, бәлки бер ел соңрак, без Гитлерны һәм ул җитәкләп килә торган явыз көчләрне җимерә алырбыз дип күз алдына китерә алам. Шуннан соң без, комсыз һәм рәхимсез Япония империясен җәзалау өчен, Кытайны күп еллар буена килгән газапланулардан коткару, үз территориябезне һәм союзникларыбызның—голландиялеләрнең территориясен азат итү өчен һәм Австралия, Яңа Зеландия һәм Һиндстан ярларыннан Япония куркынычын бөтенләйгә алып ташлау өчен шунда ук дөньяның икенче читенә күчәрбез. Бу безнең беренче һәм төп бурычыбыз булыр һәм безне бу бурычтан бернәрсә дә читкә этәрә алмас.

Шулай булса да, минемчә, Гитлерның кыйналуы, Германиянең һәм Италиянең җимерелүе моменты сугышның иң югары ноктасы булачак һәм шул вакытта безнең алдыбызда тора торган бурычлар турында яңа декларация белән чыгу вакыты килеп җитәчәк. Шул чагында без һәм безнең союзникларыбыз зур эшне төгәлләячәкбез. Әгәр дә миңа шул заманга кадәр яшәү һәм хөкүмәт башында тору насыйп булса, ул чагында мин, кабинетның ризалыгы белән, Англия милләте алдына яңа бурыч куячакмын. Япониягә каршы сугыш безнең коралы көчләребездән хәзерге бурычларга бөтенләй үзгә булган бурычларны үтәүне таләп итәчәк. Япониягә каршы сугыш никадәр генә авыр булмасын, һичшиксез, Гитлер җиңелгәннән соң армиянең бер өлеше таратылачак һәм бу хәл безнең алдыбызга гадәттән тыш авыр һәм катлаулы бурычлар китереп куячак. Без ышанабыз, Британия милләтләре, Америка Кушма Штатлары һәм Советлар Россиясе җитәкчелегендәге берләшкән милләтләр дөньяның киләчәктәге төзелеше турында кичекмәстән сөйләшүгә керешерләр. Гаепле булган дәүләтләрне һәм аларның иярченнәрен нәтиҗәле төстә коралсызландыру һәм аларның яңадан коралланууларына ирек бирмәү юлы белән, төп гаеплеләрне һәм аларның иярченнәрен судка бирү юлы белән, таланган һәм кол ителгән илләрнең техник ресурсларын һәм художество кыйммәтләрен аларга кайтарып бирүне тәэмин итү юлы белән киләчәк дөнья безне яңа сугышлардан коткарырга тиеш булыр.

Шулай ук безнең алдыбызда таланган районнарда ачлык башлануны булдырмаска тырышу кебек шундый авыр бурыч торачак. Берләшкән милләтләрне, ә кайчан да булса барлык милләтләрне дә, үз составына алачак яки аларның вәкилләре булачак халыкара оешма җитәкчелегендә Европа советы һәм Азия советы төзелер дип күз алдына китерергә мөмкин. Мин бая әйтеп үткәнчә, Япониягә каршы сугышның әле дәвам итәчәген күздә тотканда, беренче практик бурыч Европа советын төзү һәм Европа мәсьәләләрен хәл итү булачак. Без Европа советын чын нәтиҗә бирерлек лигага әйләндерергә тырышырга тиеш булырбыз (билгеле мин боларны үз исемебездән генә сөйлим). Бу лига системасына иң күп көчләр кертелер һәм аның бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү өчен югары суды булыр, шулай ук аның милли яки халыкара көчләре, яисә бу көчләрнең икесе дә булыр. Алар югары суд чыгарган карарларны үтәргә мәҗбүр итәрләр һәм агрессиянең кабатлануын һәм киләчәк сугышларга хәзерлекне бетерерләр. Билгеле, бу совет төзелгәннән соң ул киләчәктә бөтен Европаны үзенең эченә алыр һәм Европа халыклары семьясының барлык төп группалары бу советта катнаша торган вакыт килеп җитәр.

Үзләренең хокукларын яки интересларын сакларга кирәк булган күп сандагы кечкенә илләр нинди хәлдә калдылар соң? Бөек державалар белән беррәттән күп кенә дәүләтләр берләшмәләре яки конфедерацияләре төзелер. Алар үзләре сайлаган вәкилләр аркылы үзләренең карашларын белдерерләр. Мин уйлыйм, болар барысы да Англиянең, Америка Кушма Штатларының һәм Рсссиянең төп интереслары белән килештерелгән булырга тиешләр. Билгеле, безнең алда тора торган бурычларны бу илләрнең тулы ризалыгыннан һәм катнашуыннан башка үтәргә мөмкин булмаячак. Хәзер, хәтта көнбатышта да әле сугыш үзенең югары ноктасына килеп җитмәгән вакытта, ә Ерак Көнчыгыштагы сугыш әле башлангыч хәлдә генә торганда, дәүләтләрнең чикләре турында уйлау яки шул турыдагы мәсьәләне тикшерү гаять ахмаклык булыр иде. Бу, кызыксынучы бөек милләтләр күп мәсьәләләрне тикшерергә тырышмыйлар дигән сүз түгел.

Аннары Черчилль күп кенә эчке мәсьәләләргә тукталган.

Ахырда Черчилль, мин 8 нче армиянең алга баруы турында әле яңа гына генерал Монтгомеридан телеграмма алдым, дигән һәм бу армиянең алга баруы белән үзенең канәгатьләнүен белдергән.

АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 21 март. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, кичә союзниклар гаскәрләре Гафса секторында чигенүче дошманга басым ясауларын дәвам иттергәннәр. Союзниклар гаскәрләренең Макнассига таба алга китүләре хәбәр ителә. Авиация бик нык активлык күрсәткән. Ул дошманның обозларына, гаскәрләренә, артиллерия позицияләренә һәм аэродромнарына түбәннән очып һөҗүм ясаган. Сугышларда дошманның 11 самолеты атып төшерелгән.

Татарстанда

Татарстан тел әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтында

—Татарстан тел-әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты халык шагыйре Г. Тукайның яңа хатын тапты. Бу хат 1911 нче елның 20 нче октябрендә шагыйрь Сәгыйт Рәмиевкә язылган булырга тиеш. Хат, институт тарафыннан тәмам тикшерелгәннән соң, матбугатка чыгарылачак.

—Институт М. Гафуриның академик тулы җыелмасын чыгару эшенә керešте. Быел җыелманың беренче томы матбугатка тапшырылачак.

—Институтның фәнни работниклары «25 ел эчендә татар әдәбияты һәм 25 ел эчендә татар теленең үсеше» дигән фәнни очеркларны тәмам эшләп бетерделәр һәм алар шушы арада матбугатка тапшырылачаклар.

— Институт, язучы Г. Рәхим катнашы белән, фронт өчен җырлар җыентыгын әзерләп, матбугатка тапшырды. Бу беренче җырлар җыентыгына 350 халык җыры кергән. Шулардан 35 тән артыгы көйгә салынган җырлар.

Шефтагы госпитальдә

Арча районындагы «Кызыл ил» колхозы членнары, госпитальне шефка алып, эшлекле элемтә урнаштырдылар. Шушы көннәрдә колхозчыларның гомуми җыелышы тарафыннан сайланып җибәрелгән делегация госпитальдә дәваланып ятучы сугышчыларга бүләк итеп он, бәрәңге һәм башка нәрсәләр китерде, шулай ук госпитальнең эше белән якыннан танышып китте.

ХРОНИКА

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Указы буенча иптәш Павел Яковлевич Ватажников Татарстан АССР ның Азык промышленносте халык комиссары итеп билгеләнде.

ТӨЗӘТҮ

«Кызыл Татарстан» ның 20 нче март номерында «СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының «1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча дәүләт планы турында» гы карарының ике пункты түбәндәгечә төзәтеп укырга:

1. 1 нче биттәге 2 нче баганада: «в) һәрбер звенога, кагыйдә буларак, кимендә бер елга иң күбе өч-дүрт культура беркетелерлек итеп, техник, яшелчә культураларының, кукурузаның, бәрәңгенең һәм башка төрле сызма культураларның чәчү мәйданнарын звеноларга беркетүне тәэмин итәргә».

2. 2 нче битнең 4 нче баганасында: «б) җәмәгать кирәкләренә тирес бирүче колхозчыларга терлек астына салырга салам һәм торф бирергә һәм терлек астына салына торган саламны һәм торфны ташу һәм тирес чыгару өчен транспорт бирергә;»

Җаваплы редактор И. УЗБЕКОВ.

КИНОЛАРДА

«Электро» яңа документаль фильм — «Сталингард». «Унион» көндез һәм кич — «Моряк кызы». «Пионер» көндез — «Руслан һәм Людмила», «Боксерлар», кич — «Минем мәхәббәтем». «Чаткы» көндез — «Әкиятләр», кич — «Фронтка концерт».

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 9672 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 540